| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| СОВЕТ КИЛЬДЕБЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КИЛДЕБӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |


422071, Республика Татарстан, Сабинский район, с.Кильдебяк, ул. Чулпаново, 20а
тел. (84362) 45-5-50

422071, Татарстан Республикасы, Саба районы, Килдебәк авылы, Чулпан урамы, 20а йорт
тел. (84362) 45-5-50

e-mail: Kilb.sab@tatar.ru


РЕШЕНИЕ — КАРАР

13.05.2019 — № 11

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәкавыл җирлегенең 07.11.2017 елда №23 карар белән расланган "Килдебәк авыл җирлегендә төзекләндерү кагыйдәләре"нә үзгәрешләр кертү турында

ТР Саба районы прокуратурасының 12.02.2019 ел №02-01-20-2019 хаты нигезендә һәм халык алдында тыңлаулар нәтиҗәләреннән соң Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Саба муниципаль районы Килдебәкавыл җирлеге Советының 07.11.2017 елгы №23 "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәкавыл җирлегендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында" карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Кагыйдәләрнең I бүлеге 6 пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

"арбороцидлар" – агач-куак чүп үсемлекләренә каршы кулланыла торган химик матдәләр;

"Сосновский балтырганы" –эре үлән үсемлек, зонтиклылар гаиләсеннән балтырган төре. Үсемлек озак төзәлә торган көчле пешерү сәләтенә ия;

"гербицидлар" – үсемлекләрне юк итү өчен кулланыла торган химик матдәләр;

1.2. Кагыйдәләрнең III бүлеге 50 пунктын түбәндәге эчтәлекле 50.14 пунктча белән тулыландырырга:

"50.14) үләннәрне даими чабу, чүп үләннәрен һәм куакларын юк итү, бигрәк тә кеше тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыручыларын, шул исәптән Сосновский балтырганын.

Сосновский балтырганын һәм башка кеше тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыручы үсемлекләрне юк итү аларның чәчәккә бөреләнүенә һәм чәчәк ату чорына кадәр башкарылырга тиеш.

Сосновский балтырганын һәм башка кеше тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыручы үсемлекләрне юк итү түбәндәге ысуллар белән башкарылырга мөмкин:

- Химик- үсеп чыгу учакларына гербицидлар һәм (яки) арборицидлар сиптерү;
- Механик – чабу, корыган үләннәрне җыю, тамыр системасын казып алу;
- Агротехник- туфракны эшкәртү, күпьеллык үләннәр чәчү.

1.3. Кагыйдәләрнең IV бүлеге 113.5 пунктын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

"113.5. үләннәрне даими чабу (15 см-дан биегрәк булса), махсус билгеләнгән һәм чикле кулланыштагы яшелләндерелгән территорияләрдән тыш,чүп үләннәрен һәм куакларын юк итү, бигрәк тә кеше тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыручы үсемлекләрне, шул исәптән гомумкулланылыштагы җирләрдәге Сосновский балтырганын, һәм чабылган үләнне тәүлек эчендә җыештыру"

1.4. Кагыйдәләрнең IV бүлеге 114 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 2-5 абзацлар белән тулыландырырга:

"Сосновский балтырганын һәм башка кеше тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыручы үсемлекләрне юк итү аларның чәчәккә бөреләнүенә һәм чәчәк ату чорына кадәр башкарылырга тиеш.

Сосновский балтырганын һәм башка кеше тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыручы үсемлекләрне юк итү түбәндәге ысуллар белән башкарылырга мөмкин:

- Химик- үсеп чыгу учакларына гербицидлар һәм (яки) арборицидлар сиптерү;
- Механик – чабу, корыган үләннәрне җыю, тамыр системасын казып алу;
- Агротехник- туфракны эшкәртү, күпьеллык үләннәр чәчү."

2. Әлеге карар халыкка хәбәр ителгән көннән үз көченә керә һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәкавыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/kildebiak адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Килдебәкавыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарылырга тиеш.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Килдебәк авыл җирлеге башлыгы: Н.Н.Заһидуллин